АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«09» июля 2024г.** **№ 23/1**

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында вазыйфаи бурычларын үтәүләре дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге № 132 карары белән расланган Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә рөхсәт ителү Кагыйдәләре нигезендә

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында вазыйфаи бурычларын үтәүләре дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында вазыйфаи бурычларын үтәүләре дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 15.09.2021 № 45 боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан

Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары И. М. Галиевка йөкләргә.

Җитәкче Т. И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән расланды 09.07.2024 № 23/1

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында вазыйфаи бурычларын үтәүләре дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

| № | Вазыйфа исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары |
| 2 | Хокукый һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| 3 | Финанс хисабы һәм дәүләт сатып алулары бүлеге башлыгы |
| 4 | Кадрлар белән тәэмин итү буенча белгеч |
| 5 | Мобилизация эше буенча белгеч |